| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2019 п.г.т.Алексеевское № 567

**«2019-2023 елларга**
**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районында**
**кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм**
**һәм аны үстерү муниципаль программасын**
**раслау турында» Алексеевск муниципаль районы**
**Башкарма комитетының 26.03.2009 ел,**
**№ 132 карарына үзгәрешләр кертү**

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга һәм социаль Эшкуарлыкка ярдәм итү, дәүләтнеке булмаган оешмалардан социаль өлкәдә хезмәтләр күрсәтүгә һәм социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәтүнең конкурентлы ысулларын гамәлгә кертүгә керүне тәэмин итү максатларында

**карар куям**:

1. «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм һәм аны үстерү муниципаль программасын раслау турында» Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 26.03.2009 ел, № 132 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Программаны 2024 елга кадәр озайтырга;

1.2. «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм һәм аны үстерү муниципаль программасын раслау турында» муниципаль программа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «2019-2024 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм һәм аны үстерү муниципаль программасын раслау турында»;

1.3. Муниципаль программа паспортын яңа редакциядә бәян итәргә (1нче кушымта);

1.4. 4 бүлектәге " 2019-2023 елларга Алексеевск муниципаль районында сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләрен үстерү күрсәткечләре» 4.1 таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә (2 нче кушымта);

1.5. «Алексеевск муниципаль районында КУЭ үсеше программасын ресурслар белән тәэмин итү» 5 нче бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә (3 нче кушымта);

1.6. 8 бүлектәге " 2019-2023 елларга Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү программасының төп чаралары исемлеге» 7.1 таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә (4нче кушымта);

1.7. «2019-2023 елларга Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча төп күрсәткечләр» 7.2 таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә (5 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында hppt://alekseevskiy.tatarstan.ru Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Д. Васильевка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**

Кушымта №1
2019 нчы елның 16 декабреннән
Татарстан Республикасының
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенә
567 нче номерлы карары

**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | 2019-2024 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү муниципаль программасы |
| Программаның төп эшләүчесе | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге |
| Программаның максаты һәм бурычлары | Муниципаль программаның максаты: инновацион икътисадны формалаштыруда мөһим фактор буларак, кече һәм урта эшкуарлыкны нәтиҗәле эшләтү һәм үстерү өчен шартлар тудыру, шулай ук аның Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында социаль-икътисадый үсеш бурычларын хәл итүгә керткән өлешен арттыру. Кече бизнесның чагыштырма авырлыгын арттыру юлы белән район икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү.<br>Муниципаль программаның бурычлары:<br>1. Авыл җирлегендә технологик яктан яңадан коралландыруга ярдәм итү, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм җитештерү, сәнәгатьтә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, шулай ук шартлар тудыру өчен хуҗалык итүнең кече рәвешләрен тотрыклы үстерү;<br>2. Инновацион һәм конкуренциягә сәләтле азык-төлек җитештерү өчен кирәкле технологияләрне кертүгә ярдәм итү;<br>3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен финанс ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген арттыру;<br>4. Кече һәм урта эшкуарлыкка инвестицияләр җәлеп итүне стимуллаштыру.<br>5. Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итүнең гамәлдәге инфраструктурасын үстерү, яңа формалар булдыру;<br>6. Эшмәкәр кадрлар потенциалын үстерү;<br>7. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, фәнни-методик, норматив-хокукый һәм консультация белән тәэмин итү;<br>8. Эшмәкәрлек эшчәнлегенә икътисадый актив |

| | |
|---|---|
| | халыкны җәлеп итү;<br>9. Эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгульләрне социаль яклау белән тәэмин итү. |
| Программаны тормышка ашыру этаплары һәм сроклары | 2019-2024 еллар |
| Программаны башкаручылар | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, СОНКО |
| Финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслауның гомуми күләме 2102,3 млн. сум, шул исәптән: предприятиеләрнең үз акчалары хисабына – 590,5 млн. сум.<br>Еллары: 2019 - 431,9 млн. сум;<br>2020 - 351,2 млн. сум;<br>2021 - 316,2 млн. сум;<br>2022 - 328,7 млн. сум;<br>2023 - 341,4 млн. сум;<br>2024 - 332,9 млн. сум<br>Муниципаль бюджет акчалары бюджет учреждениеләре өчен товарлар белән тәэмин итүгә һәм хезмәтләр күрсәтүгә контрактлар төзү хисабына каралган, шул исәптән: районның мәктәп һәм мәктәпкәчә учреждениеләре өчен азык-төлек белән тәэмин итү, шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен төзекләндерү һ. б.<br>Программаны финанслау күләме Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы нигезендә ачыкланачак. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту | Программаны гамәлгә ашыруны координацияләү һәм контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты башкара |
| Программаны тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре | Программаны тулысынча тормышка ашыруның 2024 ел азагына кадәрге мөмкинлекләре:<br>- тулаем территориаль продуктның гомуми күләмендә микропредприятиеләрне дә кертеп, кече һәм урта предприятиеләр әйләнешен арттыру 55 проценттан да ким булмау;<br>- кече предприятиеләр, шул исәптән микропредприятиеләр тарафыннан җитештерелә торган продукция (хезмәт күрсәтүләр) әйләнеше ел саен 2 проценттан да ким булмаган үсешне саклап калу;<br>- Алексеевск муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары санының ел саен артуын саклап калу;<br>- барлык предприятиеләр һәм оешмалар |

| | |
|---|---|
| | хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача санын (башка тышкы яраштыручыларсыз), кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача санын арттыру (башка тышкы яраштыручыларсыз);<br>- ел саен 7 кече һәм урта эшмәкәрлекнең, шул исәптән үзмәшгуль эшмәкәрләрнең, ким дигәндә, 7 яңа субъектын теркәү өчен шартлар тәэмин итү;<br>- ел саен кимендә 10 берәмлек яңа эш урыннары булдыру. |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

Кушымта №2
2019 нчы елның 16 декабреннән
Татарстан Республикасының
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенә
567 нче номерлы карары

**Алексеевск муниципаль районында 2019-2024 елларга**
**сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәткечләре**

Таблица 4.1

| Күрсәткеч исеме | 2018 е. хисап | 2019 е. бәя | Фараз | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 е. | 2021 е. | 2022 е. | 2023 е. | 2024 е. |
| Ваклап сату әйләнеше, млн. сум. | 1840,7 | 1900,0 | 2009,7 | 2140,3 | 2281,6 | 2380,0 | 2499,0 |
| Җәмәгать туклануы әйләнеше, млн. сум. | 318,0 | 321,2 | 324,4 | 327,6 | 334,0 | 342,0 | 352 |
| Түләүле хезмәтләр күләме, млн. сум. | 305,3 | 319,5 | 339,2 | 362,6 | 388,5 | 410,0 | 430,5 |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

Кушымта №3
2019 нчы елның 16 декабреннән
Татарстан Республикасының
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенә
567 нче номерлы карары

**V. Алексеевск муниципаль районында КУЭ үсеше программасын ресурслар белән тәэмин итү**

Программа чараларын финанслау республика бюджеты һәм предприятиеләрнең үз акчалары хисабына планлаштырыла. Программа чараларын финанслауның гомуми күләме 2102,3 млн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән федераль бюджеттан – 793,2 млн.сум, республика бюджетыннан - 718,6 млн. сум; предприятиеләрнең үз акчалары – 590,5 млн. сум.В 2019 году (I этап) – 431,9 млн. рублей;
2020 елда (II этап) – 351,2 млн. сум;
2021 елда (III этап) – 316,2 млн. сум;
2022 елда (IV этап) – 328,7 млн. сум;
2023 елда (V этап) – 341,4 млн. сум;
2024 елда (VI этап) – 332,9 млн. сум

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

Кушымта №4
2019 нчы елның 16 декабреннән
Татарстан Республикасының
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитет житәкчесенә
567 нче номерлы карары

## VIII. Алексеевск муниципаль районында 2019-2024 елларга кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү программасының төп чаралары исемлеге

Таблица 7.1

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Программа чараларын башкаручы | Төп чараларның утәлу вакыты | Финанслау чыганаклары |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктура-сын үстерү, СЮКБО | Алексеевск муниципаль районының СЮКБО кече эшкуарлыктагы ярдәм һәм аны үстерү өлкәсендә үткәрелә торган чараларны мәгълүмати тәэмин итү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019- 2024 ее. | Акчасыз |
| | Кече эшмәкәрлек субъектлары, СЮ КБО, районның җирле үзидарә органнары катнашында «түгәрәк " өстәлләр, семинарлар, конференцияләр үткәрү;<br>эшкуарлык эшчәнлеген алып бару мәсьәләләре буенча эшкуарларга адреслы юридик ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019- 2024 ее. | Акчасыз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Эре челтәр компанияләре таләпләре турында хәбәрдарлыкны арттыру, төргәкнең сыйфатын яхшырту, реклама компаниясенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында җирле товар җитештерүчеләр катнашында «түгәрәк өстәл» ләр, семинарлар һәм киңәшмәләр үткәрү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019- 2024 ее. | Акчасыз |
| | «Лизинг-грант» программасында шәхси эшмәкәрләр, кече һәм урта бизнес предприятиеләре һәм оешмаларының катнашуы | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Алексеевск муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | 2019-2024 ее. | «Лизинг-грант» программасы буенча субсидияләр |
| | Законнарны үзгәртү белән бәйле рәвештә кече эшкуарлыкны, СЮ КБОларны үстерү мәсьәләләре буенча гамәли семинарлар уздыру | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019- 2024 ее. | Акчасыз |
| | Эшкуарларга социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре, хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча СЮ КБОларга методик һәм гамәли ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, «Алексеевск муниципаль районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ, Алексеевск муниципаль районындагы РФ Пенсия фондының ТР буенча | 2019- 2024 ее. | Акчасыз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | идарәсе, РФ Федераль салым хезмәтенең ТР буенча № 12 МРИ | | |
| | Эшкуарлык эшчәнлеге нигезләре буенча шәхси консультацияләр үткәрү, үз эшен башларга теләүче яшьләр эшкуарлыгы вәкилләре, хатын-кызлар-эшмәкәрләр, пенсионерлар өчен курслар оештыру | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Яңа эш башлаучы эшкуарларга ярдәм итү чаралары – үз бизнесларын булдыруга яңа эш башлаган эшмәкәрләргә грантлар | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Алексеевск муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, «Алексеевск муниципаль районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Декрет ялында хатын-кызлар өчен эшләнгән белем бирү проектларында; балигъ булмаган балаларның аналары, мәшгульлек хезмәтендә исәптә торучы хатын-кызлар; яшь эшкуарлар; пенсионерлар өчен белем бирү проектларында катнашу | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, «Алексеевск муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ, «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм итү фонды» КБО | 2019- 2024 ее. | Акчасыз |
| | Массакүләм мәгълүмат чаралары | Татарстан Республикасы | 2019-2024 ее. | Акчасыз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | аша халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару, гражданнарны үзмәшгульләр сыйфатында ирекле теркәү турында мәгълүмат порталы | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | | |
| | Һөнәри керемгә салым рәвешендә махсус салым режимын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар арасында аңлату эшләре алып бару | ТР буенча 12 нче номерлы РФ ФСХ МРИ | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| 2. Инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен кирәк булган ресурсларга кече һәм урта эшкуарлыкның инженерлык инфраструктурасы объектларын төзү һәм алардан файдалану системасын яхшырту | Район территориясендә сәнәгать мәйданчыгы булдыру | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019 е. | Инвестор акчасы |
| | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары объектларына инженер инфраструктурасын кертү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, подрядчы оешмалар | 2019-2024 ее. | Республика һәм җирле бюджет акчалары |
| 3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, СЮ КБОларга финанс ярдәме чараларын гамәлгә ашыру | Дәүләт хакимиятенең федераль һәм республика структураларына Алексеевск муниципаль районында кече эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме кысаларында чараларны гамәлгә ашыруда ярдәм итү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Алексеевск муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, «Алексеевск муниципаль | 2019-2024 ее. | Акчасыз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | | |
| | Район икътисадының өстенлекле юнәлешләрен үстерү максатларында, Алексеевск муниципаль районында кече эшмәкәрлек субъектларына җир кишәрлекләре, торак булмаган биналар белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү. Алексеевск муниципаль районында СЮ КБОлар катнашында җир кишәрлекләре, торак булмаган биналар белән тәэмин итүдә ярдәм итү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Кече эшмәкәрлек субъектларын муниципаль заказны үтәүгә кызыксындыру һәм җәлеп итү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «аукционнар һәм конкурслар» ММУ | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Алексеевск муниципаль районында кече эшкуарлыкны үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында салым ставкалары зурлыкларына төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр эшләү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| 4. Инвестицион проектларны | Кече эшкуарлык өлкәсендә закон һәм норматив–хокукый актлар | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль | 2019-2024 ее. | Акчасыз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| тормышка ашыру кысаларында административ киртәләрне бетерү | проектларына тәкъдимнәр, гамәлдәге норматив-хокукый актларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү | районы башкарма комитеты | | |
| | Эшкуарлык өлкәсендә муниципаль дәрәҗәдә норматив-хокукый база булдыру | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының дәүләтнеке булмаган иҗтимагый фондлар, берләшмәләр һәм ассоциацияләр белән үзара хезмәттәшлек итү ысулларын эшләү, шул исәптән кече эшмәкәрлеккә ярдәм өлкәсендә үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Кече эшмәкәрлекне үстерүгә комачаулаучы административ киртәләрне бетерү, СЮ КБО. Контроль-рөхсәт практикасын оптимальләштерү юлы белән дәүләт, кулланучылар һәм эшкуарлар мәнфәгатьләрен яраштыруны тәэмин итү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларны камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2024 ее. | Акчасыз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. Социаль эшкуарлыкка ярдәм итү, СЮ КБО | Муниципаль заказны үтәүгә социаль эшмәкәрлек субъектларын стимуллаштыру һәм җәлеп итү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «аукционнар һәм конкурслар» ММУ | 2019-2024 . | Акчасыз |
| | Муниципаль районның торак пунктларына пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы социаль эшмәкәрлек субъектларына көнкүреш хезмәтләре күрсәтүче (мунча) субсидияләр түләү. | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты, Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы | 2019-2024 ее. | Район бюджеты расланган бюджет ассигнованиеләре кысаларында |
| | Социаль эшкуарлыкка мәгълүмати-консультацион ярдәм күрсәтү, Алексеевск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше бүлеге | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Социаль эшкуарлык субъектлары катнашында «түгәрәк» өстәлләр, семинарлар, конференцияләр уздыру, эшкуарлык эшчәнлеген алып бару мәсьәләләре буенча эшкуарларга адреслы ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Социаль эшкуарлык субъектларын, СЮ КБОларны күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, конкурсларда, шул исәптән «Алексеевские перезвоны» | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2024 ее. | Акчасыз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кыңгырау чыңы фестивале, «Социаль ярминкә» хәйрия республика фестивале, «Эшкуарларның иң яхшы советы» республика конкурсына җәлеп итү | | | |
| | Эшкуарларга персоналны укытуда ярдәм күрсәтү («эшсез гражданнарны һөнәри укыту» программасы) | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, «Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | 2019-2024 ее. | Татарстан Республикасы бюджеты |
| | Эшкуарларга социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре, хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча СЮ КБО методик һәм гамәли ярдәм күрсәтү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, «Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | 2019-2024 ее. | Акчасыз |
| | Район өчен өстенлекле икътисад тармакларында үз бизнесын (үзмәшгульлеген) оештыруга инициативалы, җаваплы затларны җәлеп итү һәм аларга район башкарма хакимияте органнары тарафыннан ярдәм күрсәтү мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү максатыннан, Алексеевск муниципаль районының югары уку йортлары һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының үзара | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, «Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | 2019-2024 ее. | Акчасыз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хезмәттәшлеген оештыру | | | |
| | Дәүләтнеке булмаган оешмалар катнашында социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә муниципаль заказ урнаштыруга конкурслар системасын кертү | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «аукционнар һәм конкурслар» ММУ | 2019- 2024 ел. | Акчасыз |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

Кушымта №5
2019 нчы елның 16 декабреннән
Татарстан Республикасының
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенә
567 нче номерлы карары

**2019-2024 елларга Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча төп күрсәткечләр**

Таблица 7.2

| **Күрсәткеч исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **2018 г. отчет** | **2019 г. оценка** | **Прогноз** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2020 г.** | **2021 г.** | **2022 г.** | **2023 г.** | **2024 г.** |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны | берәмлек | 570 | 554 | 557 | 562 | 568 | 575 | 579 |
| алардан: | | | | | | | | |
| Кече предприятиеләр саны (микропредприятиеләрне дә кертеп) | берәмлек | 100 | 100 | 101 | 102 | 104 | 106 | 107 |
| Урта предприятиеләр саны | берәмлек | 7 | 7 | 7 | 8 | 8 | 9 | 9 |
| Шәхси эшмәкәрләр буларак теркәлгән физик затлар саны | кеше | 463 | 447 | 449 | 452 | 456 | 460 | 463 |
| Микропредприятиеләрне дә кертеп, кече һәм урта | млн. руб. | 5357,9 | 5204,0 | 5308,0 | 5467,2 | 5631,5 | 5744,1 | 5859,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| предприятиеләр әйләнеше | | | | | | | | |
| Шәхси эшмәкәрләрне дә исәпкә алып, кече һәм урта предприятиеләрдә мәшгульләр саны (шул исәптән үзмәшгуль гражданнарны легальләштерү) | кеше | 2407 | 2649 | 2654 | 2663 | 2669 | 2681 | 2695 |
| Кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача хезмәт хакы | сум. | 20652 | 22926 | 23385 | 24320 | 24806 | 25551 | 26062 |
| Тулаем территориаль продуктта кече һәм урта бизнесның өлеше | %. | 34,0 | 34,1 | 34,3 | 34,6 | 35,0 | 35,2 | 35,4 |
| Катнашучылары гына КУЭ субъектлары булган эре заказчыларның сатып алу өлеше | % | 78,4 | 78,6 | 78,8 | 79,0 | 79,3 | 79,5 | 79,9 |
| Кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләре эшчәнлегеннән берләштерелгән бюджетка салым керемнәре күләме | млн. сум. | 166,0 | 168,6 | 172,0 | 175,4 | 177,2 | 180,7 | 184,3 |
| Шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле бюджетына салым керемнәре күләме | млн. сум. | 93,5 | 96,1 | 99,0 | 102,0 | 104,1 | 107,2 | 109,4 |
| Сәнәгать мәйданчыгы булу | берәмлек | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Сәнәгать мәйданчыгы резидентлары саны | берәмлек | - | 2 | 3 | 3 | 4 | 4 | 5 |
| Грантлар алган яшь эшкуарлар арасыннан кече эшкуарлык субъектлары саны | берәмлек | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ваклап сату товар әйләнеше (сатуның барлык каналларында) | млн. сум. | 1840,7 | 1900,0 | 2009,7 | 2140,3 | 2281,6 | 2380,0 | 2499,0 |
| Түләүле хезмәтләр күләме | млн. сум. | 305,3 | 319,5 | 339,2 | 362,6 | 388,5 | 410,0 | 430,5 |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**